РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**посёлка городского типа**
**КУЙБЫШЕВСКИЙ ЗАТОН**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**КУЙБЫШЕВ ЗАТОНЫ**
**шәһәр тибындагы поселогы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ульяновское шоссед.8
Куйбышевский Затон , 422826
тел. (8277)59 -2-27, факс: (8277) 59-2-08
ОКПО 78702111 ОГРН 1061672000928
ИНН/КПП 1622004563/162201001

Ульяновское шоссе урамы, 8,Куйбышев Затонны штп, 422826,
тел. (8277)59 -2-27, факс: (8277) 59-2-08
ОКПО 78702111 ОГРН 1061672000928
ИНН/КПП 1622004563/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 07 » декабря 2018г.** **№ 15**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәхәр тибындагы Куйбышев Затон поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 апрелендәге “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 4 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәхәр тибындагы Куйбышев Затон поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетын карар бирә:

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәхәр тибындагы Куйбышев Затон поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 20 апрелендәге 4 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5нче бүлекнең 5.4нче пунктында:

1) 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) мөрәҗәгать итүченең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны гамәлгә ашыру яисә гамәлләрне башкару таләп итү;”;

2) түбәндәге эчтәлекле 10 пунктчасын өстәргә:

“10) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда дөрес булмавы һәм (яки) булмавы күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш;”;

1.2. 5нче бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 5.13, 5.14 пунктлар өстәргә:

5.13. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.14. Шикаять мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләнергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарка шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, шәһәр тибындагы Куйбышев Затон поселогы, Завод урамы;

- ТР, Кама Тамагы районы, шәһәр тибындагы Куйбышев Затон поселогы, Больничный переулок урамы;

- ТР, Кама Тамагы районы, шәһәр тибындагы Куйбышев Затон поселогы, Парк урамы;

- ТР, Кама Тамагы районы, шәһәр тибындагы Куйбышев Затон поселогы, Ульяновск шоссесы урамы,

шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Җитәкче Г.Р. Григорьева